# КАГЫЙДӘЛЕ ХӘРӘКӘТЛЕ УЕННАРНЫ ҮТКӘРҮ БУЕНЧА МЕТОДИК КҮРСӘТМӘЛӘР

## УЕННЫҢ ӘҺӘМИЯТЕ

Мәктәпкәчә яшьтәге бала тормышында уен аеруча зур урын били. Бу яшьтәге баланы һәрьяклап үстерүдә уен иң әһәмиятле чараларның берсе булып тора.

Төрле-төрле уеннар аркылы тәрбияче балаларда батырлык, тапкырлык һәм чыдамлык тәрбияли. Ватаныбызга, илебезнең иң яхшы кешеләренә мәхәббәт уята, аларга охшарга тырышу теләген үстерә. Уен аркылы тәрбияче баланың табигать белән кызыксынуын тәрбияли һәм табигатьне күзәтүгә теләк тудыра. Уенда балаларның кызыксынучанлыклары, хәтерләре, дикъкатьләре, сөйләм телләре дә үсә. Шулай ук балаларның фикер йөртүләрен, фантазияләрен үстерүдә дә уенның әһәмияте гаять зур.

Балалар, тирә-як тормыштан алган тойгыларны чагылдырып, уенда бик күп кызыклы нәрсәләр уйлап чыгаралар. Мәсәлән, балалар үзләре күз алларына китергән «очкыч»та очалар, тартмалардан ясалган «бозваткычлар»да йөриләр, кызылармеецлар кебек маршка атлыйлар, уенчык этләр, агач мылтыклар белән чик саклыйлар һ. б. Шулай итеп, балалар бу уеннарда үзләрен гаҗәпкә калдырган вакыйгаларны чагылдыралар һәм үзләренең тәэссоратларын, хисләрен белдерәләр.

Уенда балалар коллективка оешалар, тату уйнарга, очраган читенлекләрдән чыгу юлларын бергәләп табарга, бер-берсенә булышырга өйрәнәләр. Хәрәкәтле уеннар баланың физик яктан ныгуына, таза-сәламәт булуына, хәрәкәтләренең һәм сизү органнарының үсешенә зур ярдәм итә.

## УЕННЫҢ ТӨРЛӘРЕ ҺӘМ ТӘРБИЯЧЕНЕҢ РОЛЕ

Мәктәпкәчә тәрбия эше практикасында уеннар шартлы рәвештә ике төргә бүленәләр: 1) иҗади уеннар; 2) кагыйдәле уеннар.

Балалар иҗади уеннарда үзләренең күргәннәрен, укыганда, сөйләгәндә ишеткәннәрен, игътибарны җәлеп иткән, үзләрен кызыксындырган нәрсәләрне чагылдыралар.

Бу уеннарның эчтәлеген уен барышында балалар үзләре тудыралар. Балаларның нәрсәне ничек уйнаулары тәрбиячегә алдан билгеле булмый. Шуның өчен тәрбияче иҗади уеннарны җентекләп күзәтә һәм күзәткән вакытта, бердән, аларның эчтәлегенә, икенчедән, эчтәлекнең җәелешенә һәм барышына игътибар итә.

Шуның белән бергә, тәрбияче уен вакытында туган сорауларны, аңлашылмаучылыкларны һәм кыенлыкларны хәл итүдә киңәшләр бирә, юллар күрсәтә; уен өчен кирәкле әсбапларны ясарга булыша; тәрбия бурычларыннан һәм балаларның кызыксынуларыннан чыгып уен өчен теге яки бу төрле материалларны әзерли; материал әзерләүдә көчләреннән килерлек эшләргә балаларның үзләрен дә тарта. Кирәк булганда турыдан-туры уенга катнаша, уенның эчтәлеге тәрбияви яктан тотнаксыз булганда, аңар икенче эчтәлек бирергә тырыша. Шул ук вакытта тәрбияче балаларның табигать һәм әйләнә-тирә тормыштан алган тәэссоратларын, тойгыларын тагын да баету һәм шуның белән иҗади уеннарның темасын һәм эчтәлеген төрләндерү чараларын күрә.

Кагыйдәле уеннарда балаларны һәрьяклап үстерү бурычы башкачарак тормышка ашырыла. Чөнки аларның барлык детальләре тәрбиячегә алдан ук билгеле була. Шуның өчен бу төр уеннарны үткәрүгә тәрбияче алдан ук яхшылап хәзерләнә ала. Бу төр уеннар бик җиңел һәм күңелле формада – тәрбиячәнең үзенә бертөрле биремен үтәү характерындарак булалар.

Кагыйдәле уеннарны оештырганда тәрбиячәнең роле гаять катлаулы. Ул, балаларның яшьләренә, кызыксынуларына карап, уеннарны сайлый белергә, уенны балалар кызыксынырлык итеп бирә белергә, кагыйдәләрне дөрес юллар белән өйрәтергә, уен барышында аларның дөрес үтәлешен

күзәтергә, балаларның армауларына, ялыкмауларына, ә инде ару сизелгәндә, тыныч уенга күчү чараларын күрүгә игътибар итәргә тиеш.

Кагыйдәле уеннар үзләре тагын ике төргә бүленәләр: дидактик уеннар һәм кагыйдәле хәрәкәтле уеннар.

Дидактик уеннар, нигездә, балаларның сизү органнарын, дикъкатьләрен, вак хәрәкәтләрен, уйлап табучанлыкларын, сөйләм телләрен үстерү, табигать һәм әйләнә-тирә тормыш күренешләре һәм төрле әйберләр белән таныштыру, аларга мәгълүмат бирү өчен хезмәт итә. Балалар бакчаларында «басма уеннар» дип йөртелә торган төрле лото, парлы картинкалар, кисмә картинкалар һ. б. шушындый уеннар да дидактик уеннар эченә керәләр.

Кагыйдәле уеннарның икенче төре – хәрәкәтле уеннар. Хәрәкәтле уеннарның нигезе йөрү, йөгерү, сикерү, үрмәләү, төбәп ату, гәүдә тигезлеген саклау һ. б. шуның шикелле хәрәкәтләр ясаудан тора. Гадәттә, теге яки бу хәрәкәтле уенда югарыда күрсәтелгән хәрәкәтләрдән берсе аеруча зур урынны ала. Бу уеннар балаларның хәрәкәтчәнлеген арттыра һәм шулай ук аларның гомуми үсешләренә бик зур ярдәм итәләр.

Шулай итеп без тәрбиячենең иҗади уеннарны оештыруда, аларны үткәрүдә үз алдына бер төрле максат куюын, бу уеннар белән җитәкчелек итүдә үзенең ролен бер төрле итеп билгеләгәнен күрсәк, кагыйдәле уеннарда алга куйган максаты, алар белән җитәкчелек итүдә булган роле дә берникадәр икенче төрле булуын күрәбез. Ләкин бу бүленеш бик шартлы. Чөнки балалар бакчасы тормышында кайвакыт иҗади уеннар сизелмәстән кагыйдәле уеннар төсен алалар, киресенчә, кайвакыт кагыйдәле уеннар иҗади уен төсен ала. Мәсәлән, балаларның бик яратып, бик еш кабатлап уйнаган иҗади уеннары даими ачык бер эчтәлек ала һәм шуның белән ул кагыйдәле уен төсенә керә. Киресенчә, балаларның яратып уйнаган кызыклы кагыйдәле уеннары еш кына иҗади уен төсен ала. Әйтик, тәрбияче балаларга «Поезд» уены күрсәтте, балалар бергәләп бик кызыклы итеп уйнадылар. Уен бетүгә, балалар, төзү материалларыннан тимер юл, поезд ясап, курчакларын тартып йөртеп уйный башладылар һ. б. Шулай итеп без монда иҗади уеннар белән кагыйдәле уеннарны кискен рәвештә ике төргә бүлү мөмкин түгеллеген күрәбез.

## КАГЫЙДӘЛЕ ХӘРӘКӘТЛЕ УЕННАРНЫ ОЕШТЫРУ ҺӘМ ҮТКӘРҮ ЮЛЛАРЫ

Баланы сәламәт үстерү һәм аңа дөрес тән тәрбиясе бирүдә хәрәкәтле уеннарның нинди зур әһәмияткә ия булулары балалар врачлары, педагоглар тарафыннан күптән исбат ителгән.

Ләкин хәрәкәтле уеннарның әһәмияте бала организмын ныгыту, аның хәрәкәтләрен үстерү белән генә чикләнми. Анда бала өчен һәрвакыт бер бирем була. Бу бирем баланың һәрбер хәрәкәтенә аерым бер мәгънә бирә, ул шуның белән уенга күңелллелек кертә, шул ук вакытта һәрбер биремнең нинди дә булса берәр аерым тәрбияви кыйммәте дә була. Мәсәлән, балалар «Чыпчыклар һәм мәче» дигән уенны уйныйлар. Чыпчык булып уйнаучы балалар бу уенда чыпчык шикелле сикереп яки йөгереп кенә калмыйлар, дикъкать белән мәче килмиме дип карыйлар, тыңлыйлар, сизмәстән генә мәченең килеп тотуыннан сакла磨налар. Кирәк булганда йөгерергә, сикерергә, качарга әзер тору өчен уенның кагыйдәләрен истә калдырырга тиеш булалар. Бу уенда балалар чыпчыкларга һәм мәчегә охшатып, аларча кыланалар, димәк, уен барышында алар уенның образлары белән яшиләр. Шуның өчен алар мәче һәм чыпчыкларны хәрәкәтләр ярдәмендә ничек итеп яхшырак чагылдыру мөмкин икәнен уйлап табарга тиеш булалар.

Шулай итеп, бу уен балаларның уйлап табулары, дикъкатьләре, ихтыярлары һәм зирәклекләренең үсешенә дә зур йогынты ясый.

Күп педагоглар хәрәкәтле уеннарны иң кызыклы, иң күңелле уеннар дип йөртәләр. Бу, әлбәттә, бушка гына әйтелмәгән. Коллективта хәрәкәтләнү, бигрәк тә ачык һавада булганда, үзеннән-үзе уйнаучыларның күңелен күтәрә, шатландыра.

Уеннарны сайлаганда кайбер шартлар, мәсәлән, сезон, һава торышы исәпкә алына һәм, шушы шартлардан чыгып, яз, җәй, көз, кыш көннәрендә үткәрелә торган уеннар берникадәр төрлерәк характерда һәм төрлерәк эчтәлектә булалар. Мәсәлән, җәй көне эссе вакытта күп йөкләмәле уеннар бирергә ярамый, чөнки балалар эсседә тиз арый. Кышкы салкыннарда мондый уеннар икенче сәбәптән бирелмиләр: көчле хәрәкәтләнүдән соң бер урында хәрәкәтсез тик тору нәтиҗәсендә бала бик тиз салкын алдыра.

Уенны сайлаганда, уен үткәрү өчен булган урынның мәйданын да исәпкә алырга туры килә. Мәсәлән, кечкенә бинада күп иркенлек сорый торган, йөгереп уйный торган уеннар үткәрергә ярамый.

Хәрәкәтле уеннар дөрес оештырылганда һәм аларның эчтәлекләре тәрбия бурычларына җавап бирерлек булганда, алар балаларда үзара дусларча мөнәсәбәт, бер-берсенә булышучанлык һ. б. бик күптөрле уңай сыйфатлар тәрбияли.

Хәрәкәтле уеннарның бик күбесе сюжетлы булалар һәм алар эчтәлекләренең төзелеше, рольләр бүленеше белән һәрбер уйнаучының эше алдан билгеләнгән, үзенә бертөрле драматизация төсен алалар. Сюжетлы хәрәкәтле уеннар баланың фантазиясен, күзаллавын үстерү, шулай ук баланың кызыксынуларын тәрбияләү, күз күремен киңәйтүгә зур ярдәм итәләр. Мисал өчен, «Балалар һәм аю» уенын алып карыйк. Бу уенда аю үзе тотып алган балаларны өенә алып китә, аннан соң башкалар аюны бал белән алдыйлар һәм шулай итеп тотылган балалар аюдан котылалар. Яки уенда хәзер генә тычкан ролен гәүдәләндергән балалар үзләрен куучы мәче тарафыннан тотылгач, мәче ролен гәүдәләндерүгә күчә һ. б.

Без, шартлыча мондый хәлләр белән килешсәк тә, уендагы образларны дөрес бирүне күздә тотабыз. Уенда хайваннарны гәүдәләндергәндә, аларның гадәтләре дөрес күрсәтелергә һәм хайваннарга дөрес характеристика бирелергә тиеш. Югарыда әйтелгән «Балалар һәм аю» уенында тотылган балаларны аюның үз өенә алып китүе шартлы бер хәл булып, бала фантазиясе моны җиңел төшенә ала. Ләкин аюның селкенмихәрәкәтләнми торучы балаларга тимәве, аның бал яратуы, урманда өендә торуы, кыскача гына әйткәндә, уенның төп эчтәлеге дөреслекне аңларга ярдәм итә һәм балаларга аю турында дөрес мәгълүмат бирә.

Шулай итеп, сюжетлы хәрәкәтле уеннар тәрбия бурычларына, балаларның мәнфәгатьләренә җавап бирергә, аларның белергә тырышучанлыкларын үстерергә, образларны күз алдына дөрес китерә белергә, уенда чагылдырылган тормышның төрле күренешләренә билгеле мөнәсәбәт тәрбияләргә тиеш.

Хәрәкәтле уеннарның сюжетсыз булганнары да бар. Сюжетсыз хәрәкәтле уеннарның да шулай ук бала тәрбиясендә әһәмияте бик зур. Бу уеннар, еш кына спорт төсендә булып, балаларда кыюлык, чыдамлылык һәм хәрәкәтләрдә аныклык,